СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.б., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 262 от 23.04.2024

на № ________ от _________________

# КАРАР

Муниципаль хезмәтне оештыру
вәкаләтләрен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тапшыру буенча килешүләр төзү тәртибен раслау турында» 2015 елның 30 гыйнварындагы 288 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Арташ, Олы Кибәче, Олы Нырты, Олы Шыңар, Югары Симет, Явлаштау, Эзмә, Иштуган, Килдебәк, Курсабаш, Мишә, Мичән, Түбән Шитсу, Сатыш, Иске Икшермә, Тимершык, Шикше, Шәмәрдән, Юлбат авыл җирлекләре советларына һәм Саба шәһәр җирлеге Советына тәкъдим итәргә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең түбәндәге вәкаләтләрен Саба муниципаль районына тапшырырга:

– муниципаль хезмәт турында нигезләмәне, шулай ук муниципаль хезмәткә кагылышлы норматив-хокукый актларны раслау;

– муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс оештыру һәм уздыру;

– вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертүгә конкурс оештыру һәм уздыру;

– муниципаль хезмәткәрләргә аттестация һәм квалификация имтиханын оештыру һәм үткәрү;

– муниципаль вазыйфаларны, муниципаль хезмәткәрләрне, җирлек хезмәткәрләрен биләүче затларга өстәмә һөнәри белем бирү эшен оештыру;

– муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм бастырып чыгару өчен әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бирү;

– муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышларын үткәрү;

– муниципаль хезмәткәрләргә карата мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләрне карау;

– «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон һәм коррупциягә каршы тору өлкәсендәге башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итүдә муниципаль хезмәткәрләрнең «Җирлек» чикләүләрен һәм тыюларын, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәүләрен тәэмин итү;

– муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия утырышын оештыру һәм уздыру;

– «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында билгеләнгән тәртиптә эш башкару;

– «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм кадрлар эшендә кулланыла торган башка мәгълүмат системаларында билгеләнгән тәртиптә эшне гамәлгә ашыру;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрын һәм муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару;

– муниципаль хезмәткәрләрне тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә өстәмә түләү рәсмиләштерү өчен документлар әзерләү;

– муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр кабул итүне оештыру.

2. Әлеге карарның 1 пункты һәм килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары үз матди ресурсларын һәм финанс чараларын файдалана дип билгеләргә.

3. Советлар тарафыннан Арташ, Олы Кибәче, Олы Нырты, Олы Шыңар, Югары Симет, Явлаштау, Эзмә, Иштуган, Килдебәк, Курсабаш, Мишә, Мичән, Түбән Шитсу, Сатыш, Иске Икшермә, Тимершык, Шикше, Шәмәрдән, Юлбат авыл җирлекләре һәм Саба шәһәр җирлеге Советы кабул ителгән очракта Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы составына керүче әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне, үз вәкаләтләренә кагылышлы өлешендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына һәм Башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирлекләре башлыклары белән килешү төзергә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов